КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 10 август г.Казань № 655

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 апрель, 161 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 апрель, 161 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 28 декабрь, 628 нче; 2006 ел, 22 март, 117 нче; 2006 ел, 5 июль, 341 нче; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 21 март, 98 нче; 2007 ел, 17 декабрь, 726 нчы; 2008 ел, 5 июнь, 373 нче; 2008 ел, 14 ноябрь, 806 нчы; 2008 ел, 18 декабрь, 899 нчы; 2009 ел, 20 апрель, 239 нчы; 2009 ел, 28 декабрь, 897 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1135 нче; 2011 ел, 4 август, 633 нче; 2012 ел, 6 апрель, 279 нчы; 2012 ел, 17 сентябрь, 772 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 22 нче; 2013 ел, 26 декабрь, 1062 нче; 2013 ел, 28 декабрь, 1074 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1036 нчы; 2015 ел, 30 ноябрь, 904 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1010 нчы; 2017 ел, 31 октябрь, 829 нчы; 2017 ел, 6 ноябрь, 844 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган

Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы «м» пунктчасында күрсәтелгән гражданнар өчен юл йөрү билеты озатып йөрүче зат һәм I төркем инвалид (хезмәт эшчәнлегенә мөмкинлеге III дәрәҗәдә чикләнгән) яки инвалид бала бергә йөргәндә шәһәр җәмәгать транспортының барлык төрләрендә һәм шәһәр яны автомобиль транспортында йөрү хокукын бирә.»;

3 пунктның «м» пунктчасында «инвалид балалар» сүзләреннән соң «(һәм I төркем инвалидка (хезмәт эшчәнлегенә мөмкинлеге III дәрәҗәдә чикләнгән) яки инвалид балага бер озатып йөрүчедән артык түгел» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин